ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

30.10.2020

№ 1020

2021 елга «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү норматив чыгымнарын раслау турында»

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәплəп чыгару тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карары, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Уставы нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елга расларга:

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә

ашыруга норматив чыгымнарны, әлеге карарның 1 нче кушымтасында каралганча;

балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын 0,5 күләмендә;

2. Алабуга муниципаль районының финанс-бюджет палатасына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмаларын финанслауны;

әлеге карарның 1 нче пунктында расланган Алабуга муниципаль районының Балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә эш хакы индексы белән бер үк вакытта Алабуга муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләренең норматив чыгымнарын яңадан карауны.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазифасын башкаручы Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
"1020" 30.10.2020 ел
карарына 1 нче кушымта

Татартсан Республикасы Алабуга муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, сөциаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар, 1 укучыга бер елга, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | белем алуның беренче елы | белем алуның икенче елы | белем алуның өченче һәм аннан соңгы еллары |
| Сәнгать-эстетик | шәһәр җирлеге | 5 569 | 10 314 | 12 376 |
| | авыл җирлеге | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 5 468 | 10 126 | 12 151 |
| | авыл җирлеге | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 5 873 | 10 876 | 13 051 |
| | авыл җирлеге | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туристлык-туган төбәкне өйрәнү | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Эколого-биологик | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль - икътисади | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |